# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, №3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 3 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасында гражданның хәрби хезмәттә булуы аның инануларына яисә дин тотуына каршы килгән очракта, ул Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хәрби хезмәтне альтернатив граждан хезмәтенә алмаштырырга хокуклы.";

б) 5 пунктта "закон нигезендә" сүзләрен "федераль закон нигезендә" сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:

а) 2 пунктның дүртенче абзацында "эшчәнлеге" сүзеннән соң "федераль" сүзен өстәргә;

б) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Дини бәйрәмнәр Татарстан Республикасы законы белән эш көне түгел (бәйрәм) дип игълан ителергә мөмкин.";

3) 6 статьяның 8 пунктында "үз уставлары" сүзләреннән соң "һәм Россия Федерациясе законнары" сүзләрен өстәргә;

4) 7 статьяда:

а) беренче өлештә "Дин эшләре" сүзләрен "1. Дин эшләре" сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә:

беренче абзацта "Дин эшләре" сүзләрен "2. Дин эшләре" сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта "законнар" сүзләрен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе законнары нигезендә дини оешмаларга Татарстан Республикасы милкендәге дини билгеләнештәге дәүләт мөлкәтен тапшыру турында карар кабул итә.";

5) 15 статьяның 3 пунктында "әлеге Закон белән билгеләнгән" сүзләрен "Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән" сүзләренә алмаштырырга;

6) 17 статьяда "законнарга каршы килмәсәләр" сүзләрен "Россия Федерациясе законнарына каршы килмәсәләр" сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяда:

а) 2 пунктта "законнарга" сүзен "Россия Федерациясе законнарына" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктка "Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен өстәргә;

8) 19 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар гыйбадәт биналарында, корылмаларында һәм аларга караган территорияләрдә, дини оешмаларга әлеге максатлар өчен бирелгән башка урыннарда, дини ихтирам урыннарында, дини оешмаларның учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә, зиратларда һәм крематорийларда, шулай ук торак урыннарында тоткарлыксыз башкарыла.";

б) 4 пунктта "закон таләпләрен үтәгән килеш" сүзләрен "Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары таләпләрен үтәгән килеш" сүзләренә алмаштырырга;

9) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20 статья. **Халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә дини гореф-гадәтләр**

Дини оешмалар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләренең махсуслаштырылган челтәрен төзергә, дин тотучыларга канун таләпләре нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен медицина учреждениеләре ачарга мөмкин.";

10) 22 статьяның 2 пунктында "законнарда" сүзен "Россия Федерациясе законнарында" сүзләренә алмаштырырга;

11) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"24 статья. **Дәүләт милке, гражданнар һәм аларның берләшмәләре милке булган мөлкәттән файдалану**

1. Дини оешмалар аларга дәүләт, муниципаль, иҗтимагый һәм башка оешмалар һәм гражданнар тарафыннан бирелә торган җир кишәрлекләреннән, биналардан һәм мөлкәттән үз ихтыяҗлары өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланырга хокуклы.

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дини оешмаларга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге гыйбадәт биналарын һәм корылмаларын, аларга карый торган җир кишәрлекләре белән бергә, дини билгеләнештәге башка мөлкәтне файдалануга тапшыру түләүсез башкарыла."

12) 25 статьяда "законнар" сүзен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

13) 26 статьяда "законнар" сүзен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

14) 27 статьяда:

а) 2 пунктта "законнар" сүзен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта "хезмәт турында законнар" сүзләрен "хезмәт турында Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта "законнар" сүзен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга;

15) 29 статьяда "законнар" сүзен "Россия Федерациясе законнары" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 30 июне
№ 38-ТРЗ